Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл Советы

# КАРАРЫ

15 март 2019 ел № 112

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Кәләй авыл җирлегенә
керүче торак пунктларда
гражданнар җыены үткәрү
тәртибе турында нигезләмә

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы №131-ФЗ Федераль законның 25.1 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясын гамәлгә ашыру максатларында

Кәләй авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенә керүче торак пунктларда гражданнар җыены үткәрү тәртибе турында нигезләмәне расларга, кушымтага тәңгәл рәвештә.

2. Әлеге карарны Кәләй авылы, Специалистлар урамы, 2Д йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә, “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты, «Интернет" челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Кәләй авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

Кәләй авыл
җирлеге башлыгы В.Б. Воронин

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль район
Кәләй авыл Советының
2019 елның 15 мартындагы
№ 112 карарына кушымта

## Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенә керүче торак пунктларда гражданнар җыены үткәрү тәртибе турында нигезләмә

Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлеге территориясендә (алга таба - нигезләмә) гражданнар җыенын үткәрүгә әзерләнү тәртибе турында 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы №131-ФЗ Федераль законның 25.1 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 18.1 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнде.

### 1. Гомуми нигезләмә

1.1. Гражданнар җыены гомуми, тигез һәм турыдан-туры ихтыяр белдерү нигезендә үткәрелә.

1.2. Гражданнар җыенында торак пунктта яшәүчеләр, яшәү урыны буенча әлеге торак пунктта теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булучылар катнаша ала.

1.3. Гражданнар җыенында катнашу ирекле.

1.4. Гражданнар җыенда шәхсән катнашалар һәм аларның һәркайсы бер тавышка ия.

1.5. Гражданнар җыены турыдан-туры халык тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатында үткәрелә.

### Гражданнар җыены вәкаләтләре

1.6. Гражданнар җыены түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелә ала:

составына күрсәтелгән торак пункт керә торган авыл җирлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча әлеге торак пункт территориясен башка җирлек территориясенә кертүне күздә тоткан торак пунктта;

авыл җирлеге составына керүче торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

авыллар арасында урнашкан торак пунктта җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча халык инициативасын тәкъдим итү максатларында;

авыл торак пунктында староста кандидатурасын тәкъдим итү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

авыл торак пунктында гражданнар җыены муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнар җыелмасы очракларында каралганча, муниципаль хезмәт вазифаларын биләүгә конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар тәкъдим итү максатларында үткәрелә ала.

Гражданнарның җыенын матди һәм оештыру ягыннан тәэмин итү

1.7. Җыенны үткәрү авыл җирлеге башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

1.8. Җыенны әзерләү һәм үткәрү белән бәйле чыгымнар авыл җирлеге бюджеты хисабына башкарыла.

## 2. Гражданнар җыенын чакыру тәртибе

Гражданнар җыены үткәрү инициативасы

2.1. Торак пунктта гражданнар җыеннарын үткәрү инициативасын күрсәтә ала:

- авыл җирлеге башлыгы;
- гражданнар җыенында катнашу хокукына һәм сайлау хокукына ия, халык саны 10 кешедән дә ким булмаган торак пунктта яшәүчеләр, ягъни Россия Федерациясенең эшкә сәләтле гражданнары, 18 яшькә җиткән әлеге торак пункт территориясендә даими нигездә яшәүче гражданнар, шулай ук җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда Россия Федерациясенең халыкара килешүләре һәм федераль законнар нигезендә хокукларга ия булган торак пункт территориясендә даими нигездә яшәүче чит ил гражданнары.

2.2. Торак пунктта яшәүчеләрнең инициативалары язылган битләр (1 нче кушымта) яки гражданнар җыенын үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында инициатив төркем җыелышының беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелә, анда күрсәтелергә тиеш:

гражданнар җыенында чыгарыла торган сораулар;

гражданнар җыенын үткәрү вакыты;

гражданнар җыенын чакыру турындагы инициативаны хуплаучы гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне; паспорт яки аны алыштыручы документның сериясе һәм номеры; имзасы һәм имза кертү датасы.

2.3. Җыен үткәрү инициативасына ярдәм итәргә тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия, даими яки нигездә торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санының 5 процентын тәшкил итә, ләкин 25 имзадан да ким булмаска тиеш.

2.4. Имзалар куелган битләр, җыючы зат тарафыннан таныклану датасын, фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган датасын, паспорт номерын һәм сериясен, яшәү урыны адресларын күрсәтеп, муниципаль берәмлек башлыгына тапшырыла.

Гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул итү тәртибе

2.5. Инициативалы төркем тарафыннан билгеләнә торган гражданнар җыены, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары (2 нче кушымта), муниципаль берәмлек башлыгы инициативасы карары белән (3 нче кушымта) барлык кирәкле документлар кергән көннән соң 30 көн эчендә билгеләнә.

2.6. Муниципаль берәмлек башлыгы яки җирлек Советы максатларга ярашлы булмаган гражданнар җыеннарын үткәрүдән баш тартырга хокуклы түгел.

2.7. Гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәлә Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килергә тиеш түгел. Гражданнар җыенында каралган мәсьәләгә карата күп төрле аңлатмалар бирелүгә урын калдырылмаска тиеш, ягъни җавап бары тик бер төрле генә бирелергә тиеш.

2:8. Гражданнар җыеннарын билгеләү турындагы карарны рәсми бастырып чыгару (халыкка игълан итү) тәртибе, аны күчерү җирлек Уставы белән билгеләнә һәм муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка житкерү) өчен җирлек Уставында каралган тәртиптә басылып чыга (игълан ителә).

Җирлек башлыгы карарында яки гражданнар җыенын үткәрү турында җирлек Советы карарында түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәлә; гражданнар җыенын үткәрү вакыты һәм урыны турында мәгълүмат; җыенны оештыручы - муниципаль берәмлек органының структур бүлекчәсе турында мәгълүматлар.

2.9. Җирлекнең башкарма комитеты, җирлек башлыгы карары һәм җирлек Советы карары нигезендә гражданнар җыенын үткәрү өчен сайлау хокукына ия булган торак пункт халкы исемлеген төзи; гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерли; җирлек халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итә. (4 нче кушымта).

Җирлекнең башкарма комитеты гражданнар җыенын үткәрү өчен урыннар бирергә тиеш.

2.9.1. Торак пунктта яшәүче гражданнарга җыен үткәрү вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр ителә. Гражданнар җыенын билгеләү турында карар, гражданнар җыенын үткәрү вакыты һәм урыны, гражданнар җыенына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, мәҗбүри рәвештә халыкка хәбәр ителә.

2.9.2. Гражданнар җыенында катнашкан һәр кеше җыен булганчыга кадәр 5 көн алдан гражданнар җыенына чыгарылучы материаллар турында башкарма комитет тарафыннан чыгарылган карарлар белән таныша ала.

2.10. Гражданнар җыены турындагы нигезләмәгә таянып, гражданнар җыенын үткәрү датасын күпмедер вакыт соңгарак та күчерергә мөмкин. Гражданнар җыенын уздыру датасын күчерү турындагы карар җыен билгеләнгән көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителергә тиеш.

## 3. Гражданнар җыены үткәрү тәртибе

3.1. Җыенга       килгән гражданнар торак пунктта яшәүчеләр исемлегенә кертелгән һәм сайлау хокукына ия  булырга тиеш. Аларны теркәү  җирлек башлыгы тарафыннан  билгеләнгән  вәкаләтле зат тарфыннан  башкарыла. Исемлектә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны адресы, паспорт сериясе һәм номеры күрсәтелә.

3.2. Җыенда катнашырга теләк белдергән башка гражданнар, предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләре, матбугат һәм башка массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре,  җыенда  карала торган мәсьәләләрне хәл итү аларның эшчәнлеге белән бәйле булса, хәлиткеч тавыш бирү хокукыннан башка да рөхсәт ителә.

3.3  Торак пунктта яшүчеләр исемлегендә төгәлсезлек ачыкланган очракта, сайлау хокукына ия булган  торак пунктта яшәүче кеше  әлеге муниципаль берәмлек башлыгы  таарфыннан җыенга кертелә.

3.4.  Исмелекнең төгәл булмавын раслаучы документ булып гражданның шәхесен раслаучы документ (Россия Федерациясе гражданины паспорты, хәрби билет, чит ил гражданы паспорты, Россия Федерациясендә яшәүгә рөхсәт  язуы h.б.) була ала.

3.5.  Сайлау хокукына ия булган торак пункт халкының яртысыннан артыгы катнашканда,  карар кабул итү өчен кворум  нигезле дип санала.  Җыен уздыру өчен халык тиешенчә җыелмаганда, аны уздыруның  яңа  датасын  билгеләү муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан башкарыла. Бу очракта җыен арасындагы вакыт аралыгы ун  көннән дә иртәрәк үткәрелергә тиеш түгел.

3.6. Гражданнар җыенында тавыш бирү ачык яисә яшерен булырга мөмкин.

Тавыш бирү формасы турындагы карар гражданнар җыены тарафыннан кабул ителә.

3.7. Яшерен тавыш бирүне уздырганда гражданнар җыенында катнашу өчен теркәлгән гражданга тавыш бирү өчен бюллетень бирелә (5 нче кушымта).

3.8. Гражданнар җыенында җирлек башлыгы яисә ачык тавыш бирү юлы белән теркәлгән гражданнар санынннан гади күпчелек тавыш белән сайланган башка зат рәислек итә ала. Рәислек итүче кандидатурасын гражданнар җыенында катнашучылар тәкъдим итәргә хокуклы.

3.9. Гражданнар җыены секретарь  һәм хисап комиссиясен сайлый. Хисап комиссиясе әгъзалары саны ике кешедән дә ким була алмый. Гражданнар җыенында каралырга тиешле көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләр рәислек итүче, җирлек башлыгы, гражданнар җыенында катнашу хокукы  алган гражданнарның күпчелеге  тавыш бирү юлы белән кертелә  һәм чират тәртибендә  карала. Халык җыенында көн тәртибенә өстәмә мәсьәләләрне кертү турындагы карар  катнашучы гражданнарның яртысыннан  артыгы тавыш биргәндә  кабул ителгән дип санала.

3.10. Гражданнар җыены рәислек итүче тарафыннан ачыла. Гражданнар җыенында рәислек итүче гражданнар  җыенын үткәрүне оештыра, тәртипне хуплый, хисап комиссиясе эшен координацияли, тикшерелә торган мәсьәләләр буенча чыгыш ясау өчен сүз бирә, тавыш бирүнең билгеләнгән тәртибен тәэмин итә.

3.11. Гражданнар җыенында секретарь  тарафыннан түбәндәге беркетмә алып барыла: гражданнар җыенын үткәрү датасы һәм урыны, торак пунктында яшәүче гражданнарның гомуми саны, сайлау хокукына ия гражданнар саны,

катнашучылар саны, көн тәртибе, чыгышларның кыскача эчтәлеге, каралган мәсьәләләр буенча тавыш биргән гражданнар саны (6 нчы кушымта).

3.12. Беркетмә җыенда рәислек итүче зат һәм җыен секретаре тарафыннан имзалана һәм җирлек башлыгына тапшырыла. Беркетмәгә җыенда катнашучылар исемлеге теркәлә.

## 4. Гражданнар җыены карарлары

4.1. Гражданнар җыены карары, әгәр аның өчен сайлау хокукына ия булган гражданнарның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып торалар, җирлек башлыгы тарафыннан имзаланалар һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш (7, 8 нче кушымталар).

4.3. Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазифаи затлары гражданнар җыенында кабул ителгән карарларның җирлек Уставында билгеләнгән вәкаләтләрне чикләү нигезендә үтәлешен тәэмин итәләр.

4.4. Җыенда кабул ителгән карар җыеннарда башка карар кабул итү юлы белән юкка чыгарылырга яки үзгәртелергә, шулай ук суд тәртибендә гамәлдә түгел дип танылырга мөмкин.

4.5. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар рәсми басылып чыгарга (халыкка хәбәр итәргә) тиеш һәм муниципаль хокукый актлар өчен таләпләр нигезендә рәсмиләштерелә.

4.6. Әгәр торак пунктта яшәүчеләрнең теләге белән, кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә муниципаль хокукый актны кабул итү таләп ителсә (чыгару), җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарәнең вазифаи затлары, гражданнар җыенында кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән 15 көн эчендә тиешле муниципаль хокукый актны әзерләү һәм (яисә) кабул итү вакытын билгеләргә тиеш. Күрсәтелгән срок өч айдан да артмаска тиеш.

### Гражданнар җыены карарларын үтәү

4.7. Җыенда кабул ителгән карарлар торак пункт территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм нинди дә булса дәүләт хакимияте органнары, аларның вазифаи затлары яки җирле үзидарә органнары тарафыннан раслануга мохтаҗ түгел.

4.8. Җыенда кабул ителгән карарларның үтәлмәве закон нигезендә җаваплылыкка тартыла.